**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“25” ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә торак пунктында этаплы халык җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылы территориясендә 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Түбән Бәрәскә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); парк территориясен чистарту (үлән чабу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2) Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3) Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

4) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Түбән Бәрәскә авылында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлау, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау (Түбән Бәрәскә авылы Зеленая урамындагы күперне ремонтлау (материаллар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.

Совет Нижнеберескинского сельского поселения
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000476
ОГРН 1021606155405